**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об образовании Инвестиционного совета Республики Татарстан»**

В целях совершенствования деятельности Инвестиционного совета Республики Татарстан **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 5 июля 2012 года № УП-538 «Об образовании Инвестиционного совета Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 6 сентября 2012 года № УП-745, от 3 ноября 2012 года № УП-914, от 20 марта 2013 года № УП-242, от 29 марта 2013 года № УП-258, от 8 августа 2013 года № УП-717, от 29 апреля 2014 года № УП-440, от 27 августа 2014 года № УП-826, от 2 марта 2015 года № УП-199, от 13 октября 2015 года № УП-984, от 29 июня 2016 года № УП-553 и от 8 июня 2017 года № УП-480) следующие изменения:

а) Положение об Инвестиционном совете Республики Татарстан изложить в новой редакции согласно приложению № 1;

б) состав Инвестиционного совета Республики Татарстан изложить в новой редакции согласно приложению № 2.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
04 сентября 2018 года
№ УП-612

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан
от « 04 » сентября 2018 года
№ УП-612

# Положение
# об Инвестиционном совете Республики Татарстан

## I. Общие положения

1. Инвестиционный совет Республики Татарстан (далее – Инвестиционный совет) является коллегиальным совещательным органом по вопросам привлечения инвестиций в экономику Республики Татарстан.

2. В своей деятельности Инвестиционный совет руководствуется законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и настоящим Положением.

## II. Основные задачи Инвестиционного совета

3. Основными задачами Инвестиционного совета являются:

рассмотрение и анализ инвестиционных проектов на предмет целесообразности их реализации на территории Республики Татарстан и необходимости (возможности) их софинансирования за счет средств бюджета Республики Татарстан, местных бюджетов;

определение основных направлений развития государственно-частного партнерства и решение иных задач, направленных на совершенствование механизмов государственно-частного партнерства в Республике Татарстан;

рассмотрение вопросов взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан с международными финансовыми организациями в целях привлечения финансовых и экономических ресурсов международных финансовых организаций для реализации инвестиционных проектов и программ, направленных на социальное и экономическое развитие Республики Татарстан;

рассмотрение предложений органов государственной власти Республики Татарстан по реализации инвестиционных проектов на территории Республики Татарстан с участием международных финансовых организаций, а также предложений международных финансовых организаций по оказанию финансового и технического содействия Республике Татарстан;

рассмотрение вопросов, связанных с предоставлением инвесторам земельных участков в соответствии с земельным законодательством;

рассмотрение хода реализации и результатов инвестиционных проектов;

рассмотрение регулярных отчетов органа, уполномоченного на проведение оценки регулирующего воздействия.

## III. Основные функции Инвестиционного совета

4. В функции Инвестиционного совета входит разработка предложений по:

размещению на территории Республики Татарстан объектов в рамках реализации инвестиционных проектов и программ;

организации взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан и лиц, участвующих в инвестиционном процессе;

уменьшению административных барьеров, в том числе в части сокращения сроков и упрощения процедуры выдачи разрешительной документации;

приоритетным направлениям развития Республики Татарстан и координации финансовых и инвестиционных ресурсов на наиболее важных направлениях;

государственной поддержке инвестиционных процессов и стимулированию инвестиционной активности на территории Республики Татарстан;

установлению единых требований к основным критериям инвестиционных проектов, поддерживаемых за счет средств федерального бюджета и бюджета Республики Татарстан.

## IV. Права Инвестиционного совета

5. Инвестиционный совет в пределах своей компетенции для выполнения возложенных на него функций имеет право:

вносить предложения по совершенствованию нормативной правовой базы Республики Татарстан в области государственного регулирования инвестиционной деятельности в Республике Татарстан;

рассматривать на своих заседаниях вопросы, относящиеся к компетенции Инвестиционного совета, и принимать по ним решения;

запрашивать и получать в установленном порядке от органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан и организаций информацию в пределах своей компетенции;

вносить соответствующие предложения по вопросам, требующим принятия законов Республики Татарстан, указов или распоряжений

Президента Республики Татарстан, постановлений или распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан;

приглашать на свои заседания руководителей и должностных лиц органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан и иных органов и организаций;

создавать рабочие группы для изучения и подготовки вопросов, подлежащих рассмотрению на заседаниях Инвестиционного совета.

## V. Организация деятельности Инвестиционного совета

6. Положение об Инвестиционном совете и его состав утверждаются Президентом Республики Татарстан.

7. Председателем Инвестиционного совета является Президент Республики Татарстан. Председатель Инвестиционного совета руководит его деятельностью, утверждает состав Инвестиционного совета и рабочих групп, а также повестку заседаний Инвестиционного совета, ведет заседания Инвестиционного совета.

В отсутствие председателя Инвестиционного совета его полномочия осуществляет первый заместитель председателя Инвестиционного совета.

Организация работы по подготовке заседаний Инвестиционного совета, а также контроль за исполнением принимаемых на заседаниях Инвестиционного совета решений осуществляется секретарем Инвестиционного совета. Секретарь выполняет поручения председателя Инвестиционного совета и его заместителей по вопросам организации деятельности Инвестиционного совета, вносит предложения председателю Инвестиционного совета по составу Инвестиционного совета и рабочих групп. Секретарем Инвестиционного совета является руководитель Агентства инвестиционного развития Республики Татарстан.

8. В состав Инвестиционного совета входят представители органов исполнительной власти Республики Татарстан, организаций, осуществляющих свою деятельность на территории Республики Татарстан, а также могут входить представители территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан, общественных объединений предпринимателей, инвесторы и эксперты.

Субъекты инвестиционного процесса, общественные и другие организации вправе направить председателю Инвестиционного совета свои предложения по кандидатурам для включения в состав Инвестиционного совета.

В работе Инвестиционного совета и рабочих групп при необходимости могут принимать участие представители государственных органов, органов

местного самоуправления, общественных и других организаций, не входящие в состав Инвестиционного совета.

9. Заседания Инвестиционного совета проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в два месяца.

Заседания Инвестиционного совета считаются правомочными, если на них присутствуют не менее двух третей состава членов Инвестиционного совета.

10. Решения Инвестиционного совета принимаются простым большинством голосов путем открытого голосования присутствующих на заседании членов Инвестиционного совета и оформляются протоколом, который подписывает секретарь Инвестиционного совета и утверждает председатель Инвестиционного совета. При равенстве голосов решающим является голос председателя Инвестиционного совета. В случае отсутствия председателя Инвестиционного совета решающим голосом обладает первый заместитель председателя Инвестиционного совета. В случае несогласия с принятым решением член Инвестиционного совета вправе изложить в письменном виде свое мнение, которое подлежит обязательному приобщению к протоколу заседания.

Решения Инвестиционного совета также могут быть приняты путем проведения заочного голосования (опросным путем). Порядок проведения заочного голосования определяется решением Инвестиционного совета. Решения Инвестиционного совета, принятые путем проведения заочного голосования (опросным путем), оформляются протоколом, который подписывает секретарь Инвестиционного совета и утверждает председатель Инвестиционного совета.

11. Организационно-техническое и информационно-аналитическое обеспечение деятельности Инвестиционного совета и рабочих групп осуществляет Агентство инвестиционного развития Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 04 » сентября 2018 года

№ УП- 612

**Состав**
**Инвестиционного совета Республики Татарстан**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Инвестиционного совета |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, первый заместитель председателя Инвестиционного совета |
| Маганов Наиль Ульфатович | генеральный директор публичного акционерного общества «Татнефть» имени В.Д. Шашина, заместитель председателя Инвестиционного совета (по согласованию) |
| Минуллина Талия Ильгизовна | руководитель Агентства инвестиционного развития Республики Татарстан, секретарь Инвестиционного совета |
| Абдулганиев Фарид Султанович | министр экономики Республики Татарстан |
| Баширов Айрат Робертович | генеральный директор закрытого акционерного общества «Данафлекс» (по согласованию) |
| Гайзатуллин Радик Рауфович | министр финансов Республики Татарстан |
| Гараев Зуфар Фанилович | председатель правления Акционерного коммерческого банка «АК БАРС» (публичное акционерное общество) (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Егоров<br>Иван Михайлович | генеральный директор акционерного общества «Холдинговая компания «Ак Барс» (по согласованию) |
| Кантюков<br>Рафкат Абдулхаевич | генеральный директор общества с ограниченной ответственностью «Газпром трансгаз Казань» (по согласованию) |
| Каримов<br>Альберт Анварович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Файзуллин<br>Ирек Энварович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Фардиев<br>Ильшат Шаехович | генеральный директор открытого акционерного общества «Сетевая компания» (по согласованию) |
| Халилов<br>Руслан Рафикович | управляющий партнер общества с ограниченной ответственностью «Фонд прямых инвестиций» (по согласованию) |
| Хамаев<br>Азат Киямович | министр земельных и имущественных отношений Республики Татарстан |
| Шагивалеев<br>Тимур Наилевич | генеральный директор акционерного общества «Особая экономическая зона промышленно-производственного типа «Алабуга» (по согласованию) |
| Яруллин<br>Рафинат Саматович | генеральный директор открытого акционерного общества «Татнефтехиминвест-холдинг» (по согласованию) |

___

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Инвестиция советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-914 номерлы, 2013 елның 20 мартындагы ПУ-242 номерлы, 2013 елның 29 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2013 елның 8 августындагы ПУ-717 номерлы, 2014 елның 29 апрелендәге ПУ-440 номерлы, 2014 елның 27 августындагы ПУ-826 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-984 номерлы, 2016 елның 29 июнендәге ПУ-553 номерлы һәм 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Инвестиция советы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Инвестиция советы турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

б) Татарстан Республикасы Инвестиция советы составын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 04 сентябрь
№ ПУ-612

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «04» сентябрендәге
ПУ-612 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Инвестиция советы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Инвестиция советы) Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

2. Үз эшчәнлегендә Инвестиция советы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Инвестиция советының төп бурычлары

3. Инвестиция советының төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгын һәм аларны Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары хисабыннан уртак финанслауның кирәклелеген (мөмкинлеген) карап тикшерү һәм анализлау;

дәүләт-хосусый партнерлыгын үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү һәм Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлыгы механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән башка бурычларны хәл итү;

Татарстан Республикасының социаль һәм икътисадый үсешенә юнәлдерелгән инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыруга халыкара финанс оешмаларының финанс һәм икътисадый ресурсларын җәлеп итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының халыкара финанс оешмалары белән үзара эшчәнлеге мәсьәләләрен карап тикшерү;

Татарстан Республикасы территориясендә халыкара финанс оешмалары катнашында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тәкъдимнәрен, шулай ук Татарстан Республикасына финанс һәм техник яктан ярдәм күрсәтү буенча халыкара финанс оешмалары тәкъдимнәрен карап тикшерү;

җир турындагы законнар нигезендә инвесторларга җир кишәрлекләре бүлеп бирүгә бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның барышын һәм аның нәтиҗәләрен карап тикшерү;

җайга салу эшчәнлеге йогынтысына бәя бирүгә вәкаләтле органның даими хисапларын карап тикшерү.

## III. Инвестиция советының төп функцияләре

4. Инвестиция советы функцияләренә түбәндәгеләр буенча тәкъдимнәр эшләү керә:

инвестиция проектлары һәм программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектлар урнаштыру;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм инвестиция процессында катнашучы затларның үзара эшчәнлеген оештыру;

административ киртәләрне киметү, шул исәптән рөхсәт документларын бирү процедураларының вакытын кыскарту һәм аларны гадиләштерү өлешендә;

Татарстан Республикасы үсешенең өстенлекле юнәлешләре һәм аеруча мөһим юнәлешләрдә финанс һәм инвестиция ресурсларын координацияләү;

инвестиция процессларына дәүләт ярдәме һәм Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция активлыгын стимуллаштыру;

федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан булышлык күрсәтелә торган инвестиция проектларының төп критерийларына бердәй таләпләр кую.

## IV. Инвестиция советының хокуклары

5. Инвестиция советы үз компетенцияләре кысаларында үзенә йөкләнгән функцияләрне үтәү барышында түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген дәүләт җайга салуы өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый базасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

Инвестиция советы утырышларында үз компетенциясенә караган мәсьәләләрне карап тикшерергә һәм алар буенча карарлар кабул итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан тиешле тәртиптә үз компетенциясенә караган мәгълүматны соратып алырга;

Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары яисә боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын кабул итүне таләп итүче мәсьәләләр буенча тиешле тәкъдимнәр кертергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын чакырырга;

Инвестиция советы утырышларында карап тикшерелергә тиешле мәсьәләләрне өйрәнү һәм әзерләү өчен эш төркемнәре булдырырга.

## V. Инвестиция советы эшчәнлеген оештыру

6. Инвестиция советы турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

7. Инвестиция советының рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора. Инвестиция советы рәисе аның эшчәнлегенә идарә итә, Инвестиция советының составын һәм эш төркемнәрен, шулай ук Инвестиция советы утырышларының көн тәртибен раслый, Инвестиция советы утырышларын алып бара.

Инвестиция советы рәисе булмаган вакытта аның вәкаләтләрен Инвестиция советы рәисенең беренче урынбасары башкара.

Инвестиция советы утырышларын әзерләү буенча эшне оештыру, шулай ук Инвестиция советы утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешен контрольдә тотуны Инвестиция советы секретаре башкара. Секретарь Инвестиция советы рәисе һәм аның урынбасарларының Инвестиция советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча йөкләмәләрен үти, Инвестиция советы рәисенә Инвестиция советы составы һәм эш төркемнәре составы буенча тәкъдимнәр кертә. Инвестиция советы секретаре булып Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе тора.

8. Инвестиция советы составына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы оешмалар вәкилләре, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, эшкуарларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре, инвесторлар һәм экспертлар керә.

Инвестиция процессы субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар Инвестиция советы рәисенә Инвестиция советы составына кертүгә кандидатуралар буенча үз тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

Инвестиция советы һәм эш төркемнәре эшендә, кирәк булганда, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмаларның Инвестиция советы составына кермәгән вәкилләре катнашырга мөмкин.

9. Инвестиция советы утырышлары ихтыяҗ туган саен, ләкин кимендә ике айга бер тапкыр үткәрелә.

Инвестиция советы әгъзалары составының кимендә өчтән икесе катнашкан очракта, Инвестиция советы утырышлары гамәлгә хокуклы санала.

10. Инвестиция советы карарлары утырышта катнашкан Инвестиция советы әгъзалары тавышының гади күпчелеге белән ачык тавыш бирү юлы

белән кабул ителә һәм Инвестиция советы секретаре кул куйган һәм Инвестиция советы рәисе тарафыннан расланган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар саны тигез булган очракта Инвестиция советы рәисе тавышы хәлиткеч санала. Инвестиция советы рәисе булмаган очракта Инвестиция советы рәисенең беренче урынбасары хәлиткеч тавышка ия була. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Инвестиция советы әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул мәҗбүри утырыш беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

Инвестиция советы карарлары читтән торып тавыш бирү юлы белән дә (сораштыру юлы белән) кабул ителергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү уздыру тәртибе Инвестиция советы карары нигезендә билгеләнә. Читтән торып тавыш бирү юлы белән (сораштыру юлы белән) кабул ителгән Инвестиция советы карарлары Инвестиция советы секретаре кул куйган һәм Инвестиция советы рәисе тарафыннан раслана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Инвестиция советы һәм эш төркемнәре эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы тормышка ашыра.

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «04» сентябрендәге
ПУ-612 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Инвестиция советы составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Инвестиция советы рәисе |
| Песошин<br>Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Инвестиция советы рәисенең беренче урынбасары |
| Мәганов<br>Наил Өлфәт улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры, Инвестиция советы рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Миңнуллина<br>Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе, Инвестиция советы секретаре |
| Габделганиев<br>Фәрит Солтан улы | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Бәширов<br>Айрат Роберт улы | «Данафлекс» ябык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Гайзатуллин<br>Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гәрәев<br>Зөфәр Фәнил улы | «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Егоров<br>Иван Михайлович | «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кантюков<br>Рәфкать Габделхәй улы | «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Кәримов<br>Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Фәйзуллин<br>Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Фәрдиев<br>Илшат Шәех улы | «Челтәр компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәлилов<br>Руслан Рафикъ улы | «Турыдан-туры инвестицияләр фонды» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәче партнеры (килешү буенча) |
| Хамаев<br>Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Шаһиваәлиев<br>Тимур Наил улы | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Яруллин<br>Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

___________